ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

13.12.2024 г.Казань № 456-53/тэ-2024

Түбән Кама муниципаль районы «Водоканал» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылык китерү матдәсенә 2025 елга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2024 ел, №32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы «Водоканал» муниципаль казна предприятиесе (алга таба – «Водоканал» МКП) тарафыннан кулланучыларга бирелә торган җылылык йөртү матдәсенә әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 456-53/тэ-2024
карарына кушымта

«Водоканал» МКП тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру чыганагына 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">т/с</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы</th><th rowspan="2">Тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре</th></tr>
<tr><th>су</th><th>пар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Кулланучыларга җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Түбән Кама муниципаль районы</td></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td rowspan="2">«Водоканал» МКП</td><td rowspan="2">бер ставкалы, сум/куб.м</td><td>01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр</td><td>148,75</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр</td><td>167,59</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге